РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ НИЖНЕКАМСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423586, г. Нижнекамск, пр. Строителей, 12
тел./факс (8555) 41-70-00

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТҮБӘН КАМА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

423586, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
тел./факс (8555) 41-70-00

РЕШЕНИЕ

КАРАР

№ 52

2022 елның 15 сентябре

Түбән Кама муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын раслау турында» 2017 елның 15 декабрендәге 69 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент» Федераль законына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 июлендәге 276-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын раслау турында» 2017 елның 15 декабрендәге 69 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

7.3.16 пунктында «җирлекләр» сүзен «торак пунктлар» сүзләренә алмаштырырга;

7.3.18 пунктында «гомуми челтәрдәге тимер юллар» сүзләрен «тимер юллар» сүзләренә алмаштырырга, «гомуми челтәрдәге тимер юлында» сүзләрен «тимер юллар» сүзләренә алмаштырырга;

7.3.22 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Янгынга каршы аралык янгынның урманнардан биналарга һәм корылмаларга кадәр таралмавын тәэмин итәргә тиеш.»;

7.3.23 пунктында «урманчылыкларда» сүзләрен төшереп калдырырга;

7.3.37 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.3.37. Янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганаклары буларак, үзәкләштерелгән һәм (яки) үзәкләштерелмәгән су белән тәэмин итү системалары, су объектлары, шулай ук янгын сусаклагычлары файдаланылырга мөмкин.»;

7.3.38 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.3.38. Янгынга каршы су белән тәэмин итүне, су белән тәэмин итү системалары җиһазларын, сүүткәргеч челтәрләрен, ясалма сулыкларны һәм янгын сусаклагычларын тәэмин итү зарурлыгы, янгынга каршы тору өчен су объектларыннан файдалану «Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент» 2008 елның 22 июлендәге 123-ФЗ номерлы Федераль закон белән, ә аларны урнаштыруга таләпләр янгын куркынычсызлыгы буенча норматив документлар белән билгеләнә. Су объектларының һәм янгын сусаклагычларының су запасы, янгын сүндерү вакытын исәпкә алып, биналар һәм корылмаларның янгын сүндерү өчен исәпләнгән чыгымнарын тәэмин итәргә тиеш.»;

7.3.40 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.3.40. Торак пунктлар территорияләрендә янгын сүндерү депосы биналарын шәһәр торак пунктларында чакыру урынына беренче бүлекчәнең килеп җитү вакыты 10

минуттан, авыл торак пункитларында 20 минуттан артмаска тиеш дигән шарттан чыгып урнаштырырга кирәк.»;

4.7.51, 4.7.52, 7.3.2 пунктларын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны төзелеш, җир төзелеше, торак-коммуналь хуҗалык һәм транспорт буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгы вазыйфаларын башкаручы,
Башлык урынбасары А.В.Умников